| БАВЛИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

14.08.2023 ел Баулы шәһәре № 107

Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советының
2019 елның 27 мартындагы 103 номерлы
"Татарстан Республикасының “Баулы шәһәре”
муниципаль берәмлеге, муниципаль милкендә
урнашкан өченче зат хокукларыннан азат һәм кече һәм
урта эшкуарлык субъектларына милек һәм (яки)
файдалануга бирү өчен билгеләнгән исемлекне
раслау турында “ карарына үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 3 пунктына ярашлы, исемлекне актуальләштерелүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын тәшкил итүче оешмаларга, озак вакытлы нигездә (шул исәптән аренда хакының ташламалы ставкалары буенча) үзләштерү һәм (яки) файдалану максатларында, шулай ук Баулы шәһәр Советының 2019 елның 27 мартындагы 103 номерлы карары белән расланган, кече һәм урта эшкуарлык субъектлары милкенә түләүле нигездә читләштерүләр максатында, (Баулы шәһәр Советының 2019 елның 16 октябрендәге 116 номерлы, 2020 елның 28 августындагы 141 номерлы, 2020 елның 23 октябрендәге 13 номерлы, 2021 елның 7 апрелендәге 28 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) өченче зат хокукларыннан азат булган милек исемлегенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

12-нче пункт белән тулыландырырга:

| № п/п | Милекнең атамасы | Төп характеристикалары | Урнашкан урыны (адресы) | Баланс тотучы |
|---|---|---|---|---|
| 12. | Шәһәр китапханәсе бинасы 1-нче номерлы филиал | 293,5 | 16:55:010305:462 Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Баулы шәһәре, Ваһапов урамы, 54 | Татарстан Республикасы “Баулы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында http://www.bavly.tatarstan.ru.адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы шәһәр Советының икътисади үсеш, эшмәкәрлек, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Баулы шәһәре Мэры,
Шәһәр Советы рәисе И.И. Гозәеров